ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 28 һәм 33 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 28 статьяда:

а) 2 өлешнең беренче абзацында «махсус рөхсәт бирү» сүзләрен «махсус рөхсәтне кәгазь чыганакта бирү» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән махсус рөхсәтне электрон рәвештә бирү федераль башкарма хакимиятнең юл хуҗалыгы өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү һәм дәүләт мөлкәте белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыручы органы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә йә ул вәкаләт биргән ведомство буйсынуындагы учреждение аша башкарыла.»;

в) 7 өлешнең беренче җөмләсендә «,шул исәптән электрон рәвештә дә,» сүзләрен һәм икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

г) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Вәкаләтле орган билгеләгән даими маршрутлар исемлекләре аның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.»;

2) 33 статьяда түбәндәге эчтәлекле $3^4$ өлеш өстәргә:

«$3^4$. Региональ, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юлларыннан, мондый автомобиль юлларының түләүле участокларыннан йөргән өчен түләү Федераль законның 40 статьясындагы 12 өлеше белән билгеләнгән таләпләр нигезендә тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарә органнары тарафыннан раслана.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда үз көчләренә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «а» һәм «б» пунктчалары 2021 елның 21 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «в» һәм «г» пунктчалары 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. 2023 елның 1 гыйнварыннан алып «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 28 статьясындагы 2 өлеше нигезләмәләре кулланылмый.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 02 декабрь
№ 83-ТРЗ